күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

## Мәктәп яңалыклары...

6 нчы чыгарылыш
28 нче февраль




БУ САНДА:



| | |
|---|---|
| Бәйрәм белән! | 1 |
| Строй һәм җыр смотр-конкурсы | 2 |
| 21 февраль – Халыкара туган тел көне | 3 |
| Муса Җәлилнең тууына -114 ел | 4 |



**Ватанны саклау - һәркемнең изге бурычы. Ватанны саклау өчен кеше гыйлемле булырга, тарих сабакларына төшенергә, киләчәкне акыл белән кора белергә тиеш.**

**Ватанны саклаучылар көне - кыюлык, намус һәм батырлык көне. Бу көчле рухлылык, чын ир-егетләрнең батырлык, намус һәм абруй кебек сыйфатларга ия булуларын раслый торган бәйрәм.**

**Илебез сагында торучы кыю, курку белмәс егетләребез барында илебез тыныч, күгебез гел аяз булыр. Әтиләре, абыйлары үрнәгендә патриотик рухта тәрбияләнгән яшь егетләребезгә, хәрби хезмәтләрен үтәгәндә, туган якта калган якыннарының тынычлыгын саклап, үзләрен яхшы яктан гына күрсәтерләр, дигән ышаныч белдерәбез.**

**Ватан алдындагы изге бурычларын үтәүче барлык ир-егетләрне, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, хәрби хезмәткә хәзерләнүче барлык ир-егетләрне Ватанны саклаучылар көне белән чын күңелдән котлыйбыз.**

**Күк йөзе һәрчак аяз булсын. Сезгә кояштай озын гомер,корычтай нык сәламәтлек, яңа яуган ак кардай бәхетләр, иге-чиге булмаган шатлыклар, әти-әни сүзен тыңлап тәртипле, әдәпле, белемле, әхлаклы, тырыш егетләр булып үсүгезне телибез!**

# Строй һәм җыр смотр-конкурсы




Хөрмәтле укытучылар, кадерле укучылар аз гына тарих битләренә күз салып алыйк...

23 нче февраль… Бу бәйрәмгә инде 100 елдан артык. 100 елдан артык инде кешелекнең иң көчле яртысы көч, түземлелек, патриотизм һәм мәрхәмәтлелек бәйрәмен билгеләп үтә. Нарва һәм Псков янында немец басып алучыларын җиңү хөрмәтенә 1918 елның 23 февралендә Кызыл Армия көне бәйрәмен билгеләп үтү турында декрет чыгарыла. Соңыннан бу бәйрәм Совет Армиясе һәм хәрби диңгез Флоты көне итеп үзгәртелә. Ә хәзер берничә ел индеВатанны саклаучылар көне буларак билгеләп үтелә. Россиядә элек – электән үк Ватанны саклаучы иң хөрмәтле һәм изге профессия булып саналган. Ватанга хезмәт итү ул - ул халыкның тыныч тормышын саклау, үз иленең намусын саклау.

Армия сүзе латинчадан “коралландырылган” диеп тәрҗемә ителә. Ләкин армия коралы белән генә түгел, ә үзенең кыю, батыр солдатлары белән көчле. Ә тыныч вакытта безнең армия Россиянең унар меңләгән километр коры җир, су һәм һава чикләрен саклый.

Мәктәбебез дә бу көннәрне һәр ел искә ала. Хәрби-патриотик айлыгы кысаларында мәктәбебездә, 19 нчы һәм 20 нче февраль көннәрендә, строй һәм җыр смотр-конкурсы булып узды. Сәламләү сүзе белән мәктәбебез директоры Абдуллина Динә Альберт кызы чыгыш ясады. Ул егетләрне, ир-атларны бәйрәм белән тәбрикләде.

Бәйрәм 2 -10 нчы сыйныф укучыларының смотрга әзерлекләре турындагы докладлары белән дәвам итте. 2 -10 сыйныф укучылары тигез сафлар белән жюри һәм тамашачылар яныннан уздылар, хәрби– патриотик җырлар башкардылар. Үзләренең төрле командаларны дөрес башкарулары белән сокландырдылар. Хәрби пилоткалардан, хәрби җыр белән алар зал буйлап сафта йөреп күрсәттеләр, һәркемгә бәйрәм рухы бүләк иттеләр. Жюри бөтен отделениеләрнең дә әзерлеген югары бәяләде.











# 21 февраль – Халыкара туган тел көне




Берләшкән Миллəтләр оешмасы карары белән һәр елны 21 февраль – Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә. Һәр халыкның – үз тарихы, үз кыйбласы, үз гореф-гадәтләре, үз теле. Аларның һәркайсы бик тә кадерле, бик тә газиз. Кеше үз төбәгенең, ыруының тарихын белергә, шәҗәрәсен өйрәнергә тиеш. Телебез исә әни кебек аеруча сөекле, шуңа да мәңге аерылгысыз, изге төшенчә. Кешегә нәселенең, халкының асыл гадәт-сыйфатларын да иң әүвәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә ана бирә. Туган тел – дөньяны ганып белү, өйрәнү-төшенү өчен тылсымлы алтын ачкыч, могҗизалы асыл корал – үзара аралашу коралы. Адәм баласының иң изге, иң мөкатдәс хисләренең берсе – туган телгә гаме, хөрмәте булу.

Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд. кеше сөйләшә, инглиз телендә — 478 млн, һинд телендә — 437 млн, испанда — 392 млн, рус телендә — 284 млн, гарәптә — 225 млн, португалда — 184 млн, француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.

Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе- тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу - безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашуыбыз теле. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип танына, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга тиешбез.

Тел - халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау кагылмасаң чыңламый. Әйдәгез әле әнә шул кыңгырауны ешрак чыңлатыйк




И туган тел!
Сине Әнкә итеп
Йөрәгендә саклый бу халык.
Таралган ул...
Әгәр син булмасаң,
Бетәр иде күптән югалып.
Югалмадың,
Югалтмадың безне-
Халык исән калган син барга.
Бу дөньяга күзебезне ачтың,
Хакыбыз юк кабат йомарга.

Алтын җыйма, йортлар куйма,
Мираска дип балаңа.
Иң кадерле мирас итеп,
Туган телең бир аңа.
Онытмагыз, бу дөньяда
Иң зур бүләк бер генә -
Көмеш чыңлы, талгын моңлы
Газиз туган тел генә.

# 14 нче февраль – Гашыйклар көне



Нәрсә соң ул мәхәббәт? Бөтен даһи нәрсәләр гади булган кебек, ярату хисен дә катлаулы формулалар ярдәмендә аңлату мөмкин түгел. Әгәр син үзеңне бәхетле итеп тоясың икән, димәк, син яратасың! Сөю хисендә янасың икән, димәк, сине дә яраталар! Мәхәббәтне төрле кеше төрлечә аңлый...





## Февраль ае бәйрәмнәре

2 февраль — Сталинград сугышы көне.
2 февраль — Байбак (сурок) көне.
8 февраль — Рәсәй Фәне көне.
10 февраль — Пушкинны искә алу көне.
14 февраль — Изге Вәли көне.
15 нче февраль – Муса Җәлил туган көн,
15 февраль — Әфганстаннан Совет гаскәрләрен чыгару көне.
15 февраль — Интернационалист сугышчыларны искә алу көне.
21 февраль — Халыкара туган тел көне.
23 февраль — Ватанны саклаучылар көне.

Бәйрәм артыннан бәйрәм... Алар һәрбер кеше күңелендә онытылмаслык тирән эз калдыргандыр. Шуларның берсенә киңрәк тукталыйк.

Бер матур җыр идең син үзең дә,
Гомерең дә калды җыр булып..

1906 нчы ел, 15нче февраль – герой-шагыйрь - Муса Җәлилнең тууына -114 ел.

Муса Җәлил — безнең һәрберебез өчен изге исем. Ул – чын мәгънәсендә, каһарманлык билгесе, Ватанга чиксез тугрылык һәм мәхәббәт символы. Көрәшче шагыйрь, ялкынлы патриот, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең гомере кыска һәм фаҗигале булды. Әмма аның батырлыгы, иҗади мирасы татар халкының олы тарихында, бөтен илебез язмышында тирән эз калдырды.

М. Җәлилнең әдәби мирасы күп милләтле совет әдәбиятының кыйммәтле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра.

Аның исемен татар халкы мәңгеләштерде. Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет академия театры Муса Җәлилисемен йөртә. Башкалабызның үзәгендә аңа һәйкәл куелды. Ул яшәгән фатирда музей ачылды. Татарстанда Җәлил исемендәге бистә бар. Муса Җәлилгә багышлап романнар, поэмалар, опера, җырлар, сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителде.

Җәлил исемен илебез халкы горурлык белән искә ала. Һәр буын аны йөрәгендә саклый. Аның көрәше һәм эшчәнлеге – күпләр өчен кыюлык һәм батырлык үрнәге.

Шагыйрьне үтерсәләр дә, фашистлар аның ялкынлы җырларын, көчле рухын юк итә алмадылар. Муса Җәлил илгә җыр булып кайтты.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Редакциянең адресы:420101, Казан шәһәре,Тулпар урамы, 2. Тел. 89050229576 Тираж – 50 экз.
Редколлегия:
Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камилия, Вәлиева Диләрә,Корчагина Яна, Хәсәнова Адилә, Мельникова Аделина